
Әдәби ядкарьләребезне барлаганда



Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты», «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / Төз. Мәрданов Р. Ф. – Казан, 2008. – «Татар археографиясе» сериясе. – 1 нче китап. – 88 б.

Татарстан Милли китапханәсе «Татар археографиясе» сериясен башлап җибәрде. Серияне гамәлгә куючыларның төп максаты — Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган, моңарчы басылмаган тарихи, әдәби һәм башка язма истәлекләрнең текстларын хәзерләп дөньяга чыгару, татар палеографиясенә һәм археографиясенә багышланган мәкаләләр җыентыкларын бастыру.

Сериянең беренче китабында XVII йөз татар шагыйре Мәүла Колыйның ике поэмасы нәшер ителде. Әсәрләрне басмага 1990 нчы елларда Татарстанның Әгерҗе районында табылган бердәнбер нөсхәләре нигезендә филология фәннәре кандидаты, археограф Р. Ф. Мәрданов хәзерләде.

Беренче поэмага бастыручы тарафыннан шартлы рәвештә «Береккәннәр сыйфаты» дигән исем куелган. Бу әсәр «берлектә — көч» дигән мотив белән сугарылган. Поэмада хәлиткеч роль хатынга йөкләнгән, бу исә урта гасыр әдәбиятларында сирәк очрый торган күренеш. Кулъязма җыентыктагы икенче әсәр — «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» поэмасының аз өлеше генә сакланган. Шулай да, Мәүла Колыйның бу әсәре да шактый күләмле һәм гыйбрәтле сюжетка корылганлыгы чалымлана.

Китапта бу ике әсәрнең хәзерге татар язуына күчерелмәсе, хәзерге татар әдәби теленә юлга-юл күчерелмәсе, файдаланылган кулъязманың факсимилесе һәм тасвирламасы бирелгән. Китапны академик М. Г. Госмановның өйрәнүчеләргә сирәк насыйп була торган бу әдәби ачышка багышланган мәкаләсе йомгаклый.

Башлап җибәргән бу кирәкле эшләрендә коллегаларыбызга уңышлар телибез һәм киләчәктә «Татар археографиясе» сериясендә татар әдипләренең моңарчы өйрәнелмәгән башка күптөрле әсәрләре һәм кызыклы тарихи язмалар дөнья күрер дип ышанабыз.

Мансур Ильясов

РЕЗЮМЕ
В рецензии М. Ильясова анализируется книга кандидата филологических наук Р. Марданова «Мәүла Колый поэмалары», в которой опубликованы две новонайденные поэмы татарского поэта XVII в. Мавла Кулыя.